СОВЕТ ШАДЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д.18, с. Шадчи,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422145

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘДЧЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Яшьләр ур., 18 нче йорт, Шәдче авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422145

тел.(факс): (85563) 2-52-24; e-mail: Shad.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар — Решение

02 нче октябрь 2017 ел — № 1-25

### Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм аларны куллану буенча җирле референдум үткәрү көнен билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 2 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-Ф3 номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Җирле референдум турында» 2004 ел, 23 март, 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Шәдче авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, Шәдче авыл җирлеге башкарма комитетының “Референдум уздыру инициативасы турында” 2017 нче елның 20 че сентябрендә кабул ителгән 14 нче номерлы карары, Шәдче авыл җирлеге Советының “Референдум уздыру инициативасы турында” 2017 нче елның 20 нче сентябрендә кабул ителгән 2-24 нче номерлы карары, Шәдче авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Шәдче авыл җирлегендә гражданнардан узара салым акчасын җыю һәм куллану кагыйдәләре” 2014 нче елның 2 нче апрелендә кабул ителгән 2-33 нче номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге Советы К А Р А Р КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм аларны куллану буенча җирле референдум үткәрү көнен 2017 нче елның 19 нче ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби

хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия  Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2018 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

**1.Җирлек  халкын су белән тәэмин итүне оештыру:**

Вахит торак пунктында  су белән тәэмин итү челтәрләрен алыштыру.

**2.Авыл җирлеге территориясен төзекләндерүне оештыру:**

Юкәче һәм Яңа Мочалкино торак пунктларында чишмәләрне төзекләндерү.

**3. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел пожар куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын булдыру :**

Иске Мочалкино торак пунктында пожар гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру.

**4. Җирлекнең торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

Шәдче торак пунктында ( Г.Тукай урамы- 600 м., М.Җәлил урамы – 600 м.), Ямаш торак пунктында ( Тынычлык урамы- 650м.) юлны вакташ җәеп ремонтлау;

« ӘЙЕ »     « ЮК »

4. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге башлыгы В.В.Шрыковка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Шәдче авыл җирлеге башлыгы,
Совет председателе /В.В.Шрыков/